| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02.02.2026 Олы Кайбыч ав. № 75

2026 елга күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен үзгәртүнең иң чик индексы күләмен раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2018 елның 06 апрелендәге 213/пр номерлы «Торак урын милекчеләре өчен торак урынны карап тоткан өчен күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен түләү күләмен билгеләү буенча, торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү турында, шулай ук мондый түләүнең иң чик индексларын билгеләү тәртибен билгеләү буенча методик тәкъдимнәрне раслау турында» боерыгы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен үзгәртүнең иң чик (максималь) индексы күләмен 2026 елның 01 гыйнварыннан 2026 елның 30 сентябренә кадәр 1,7 процент күләмендә, 2026 елның 01 октябреннән 2026 елның 31 декабренә кадәр 13,4 процент күләмендә билгеләргә.
2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда бастырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесенең төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык буенча урынбасары Е.Г. Давыдовага йөкләргә.

Җитәкче А.Н. Макаров